КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 май г.Казань № 488

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кайбер башкарма органнары вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру турында» 2021 ел, 5 май, 311 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кайбер башкарма органнары вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру турында» 2021 ел, 5 май, 311 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 23 октябрь, 997 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «органнары» сүзеннән соң «(ведомствосы буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре)» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра дип билгеләргә:

физик затларга хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне, шулай ук аларга бәйле булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне исәпләү һәм аларны күчерү, бюджет исәбен алып бару (бюджет хисаплылыгын, бюджет исәбе мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла торган башка мәҗбүри хисаплылык төзүне һәм тапшыруны кертеп), мондый хисаплылыкны тиешле дәүләт органнарына кертүне тәэмин итү буенча:

2022 елның 1 гыйнварыннан – 1 нче кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына карата;

2022 елның 1 июненнән – 2 нче кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә карата;

2022 елның 1 августыннан – 3 нче кушымтада күрсәтелгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә карата;

2023 елның 1 гыйнварыннан физик затларга хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне, шулай ук аларга бәйле булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне исәпләү һәм аларны күчерү буенча – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына карата.»;

3 пунктның икенче абзацында «үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектлары белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары (ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре) (алга таба – үзәкләштерелгән исәпкә алу субъектлары) белән» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәргә:

«в) Министрлыкның үзәкләшкән вәкаләтләрне үтәү йөкләнгән вазыйфаи затлары түбәндәгеләр өчен җавап бирә:

бюджет яки бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күрсәткечләрен бозып күрсәтү, әгәр мондый бозып күрсәтү үзәкләштерелгән исәпкә алу субъекты тарафыннан Министрлыкка тапшырылган хуҗалык тормышының дөрес булган беренчел исәпкә алу документлары нигезендә бухгалтерлык исәбен алып бару нәтиҗәсендә җибәрелгән булса;

физик затларга хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне, шулай ук аларга бәйле булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне исәпләү һәм аларны күчерү, бюджет хисаплылыгын, бюджет исәбе мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла торган башка мәҗбүри хисаплылык төзү һәм тапшыру, мондый хисаплылыкны тиешле дәүләт органнарына кертүне тәэмин итү буенча йөкләмәләрне үтәү сроклары сакланылмау;

физик затларга хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне, шулай ук аларга бәйле булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне исәпләгәндә һәм аларны күчергәндә законнар нормалары үтәлмәгәндә.»;

әлеге карарга кушымтаның нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 май, 311 нче карарына 1 нче кушымта»;

әлеге карарга 2 нче һәм 3 нче кушымталар (карарга теркәләләр) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләрендә штат саны кыскартылуга бәйле рәвештә, законнар нигезендә кирәкле оештыру чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 5 май, 311 нче
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 26 май, 488 нче
карары редакциясендә)

2022 елның 1 июненнән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан физик затларга хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне, шулай ук аларга бәйле булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне исәпләү һәм аларны күчерү, бюджет исәбен алып бару (бюджет хисаплылыгын, бюджет исәбе мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла торган башка мәҗбүри хисаплылык төзүне һәм тапшыруны кертеп), мондый хисаплылыкны тиешле дәүләт органнарына кертүне тәэмин итү вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре
исемлеге

1. «Актаныш районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
2. «Әлки районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
3. «Апас районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
4. «Минзәлә районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
5. «Теләче районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
6. «Киров районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 5 май, 311 нче
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 26 май, 488 нче
карары редакциясендә)

2022 елның 1 августыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан физик затларга хезмәт өчен түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне, шулай ук аларга бәйле булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне исәпләү һәм аларны күчерү, бюджет исәбен алып бару (бюджет хисаплылыгын, бюджет исәбе мәгълүматлары нигезендә формалаштырыла торган башка мәҗбүри хисаплылык төзүне һәм тапшыруны кертеп), мондый хисаплылыкны тиешле дәүләт органнарына кертүне тәэмин итү вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре
исемлеге

1. «Азнакай шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
2. «Аксубай районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
3. «Алексеевск районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
4. «Әлмәт шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
5. «Арча районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
6. «Әтнә районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
7. «Баулы шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
8. «Балтач районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
9. «Бөгелмә шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
10. «Буа шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
11. «Югары Ослан районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

12. «Биектау районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
13. «Чүпрәле районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
14. «Алабуга шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
15. «Зәй шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
16. «Зеленодольск шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
17. «Кайбыч районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
18. «Кукмара районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
19. «Лаеш районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
20. «Лениногорск шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
21. «Мамадыш районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
22. «Менделеевск районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
23. «Мөслим районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
24. «Яр Чаллы шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
25. «Түбән Кама шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
26. «Яңа Чишмә районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
27. «Нурлат шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
28. «Питрәч районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
29. «Балык Бистәсе районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
30. «Саба районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
31. «Сарман районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
32. «Спас районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.
33. «Тәтеш районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

34. «Чирмешән районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

35. «Чистай шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

36. «Ютазы районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

37. «Казан шәһәренең Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

38. «Авиатөзелеш районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

39. «Вахитов районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

40. «Мәскәү районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

41. «Яңа Савин районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.

42. «Идел буе районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе.